КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 апрель г.Казань № 477

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышын яхшырту чаралары турында» 2014 ел, 10 июнь, 394 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышын яхшырту чаралары турында» 2014 ел, 10 июнь, 394 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктның икенче – дүртенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

4 һәм 5 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта татар текстында «2014 елның 1 сентябренә кадәр» сүзләрен «кирәк булуга карап» сүзләренә алмаштырырга, «озак сроклы тармак программаларын эшләргә» сүзләрен «тармак программаларын актуальләштерергә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче һәм дүртенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

в пункте 8:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацта «күрелгән чаралар» сүзләрен «эш итү чаралары» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта:

дүртенче абзацта «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «Россия Федерациясе Социаль иминият фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче һәм тугызынчы абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

11 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин